ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

10 август 2016 ел

№ 4150

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет төзү турында

Күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын яхшырту максатында, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез рәвештә бәяләүне үткәрү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын формалаштыру турында» 2013 елның 21 октябрендәге 793 нче карары, Башкарма комитетның «Социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын формалаштыру турында» 2014 елның 21 мартындагы 1483 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет составын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) муниципаль учреждениеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез рәвештә бәяләүнең якынча критерийларын, 3 нче кушымтада каралганча.

2. Вәкаләтләр йөкләргә:

1) рәсми сайтта мәгълүмат имзалау буенча – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка;

2) рәсми сайтта мәгълүмат урнаштыру буенча – «Мәгълүмати технологияләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы О.Е. Фоминга.

3. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет төзү турында» 2014 елның 21 июлендәге 4253 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2016 елның 10 августындагы
4150 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Яр Чаллы шәһәрендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен формалаштырганда һәм тормышка ашырганда, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, җәмәгать берләшмәләре һәм дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмаларның хокукларын, гражданнарның сыйфатлы хезмәт күрсәтүгә хокукларын, аларның нәтиҗәлелеген һәм куркынычсызлыгын тормышка ашыруга һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләре чикләрендә халыкка муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контрольне камилләштерүгә бәйле мәсьәләләрне карап тикшерә торган киңәшмә органы булып тора.

2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Башкарма комитет карары белән раслана.

3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм боерыкларына, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге нигезнамәгә таянып эш итә.

4. Иҗтимагый совет карарлары рекомендация характерына ия.

5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген түләүсез нигездә гамәлгә ашыра.

6. Иҗтимагый советның эше, катгый рәвештә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларына туры китереп, ачыклык һәм партнерлык принципларына нигезләнгән.

7. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген гражданнар җәмгыяте институтлары вәкилләренең, җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының үзара кызыксынуы нигезендә гамәлгә ашыра.

2 бүлек. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

8. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

1) гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, хокукларын һәм ирекләрен, җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре чикләрендә тиешле өлкәләрдә җәмәгать берләшмәләре һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмалар хокукларын яклау;

2) эшчәнлекнең тиешле өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләр буенча төп юнәлешләрне эшләүгә җәмәгать, профессиональ һәм иҗади берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итү, Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклык принцибын тормышка ашыру;

3) Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатына җәмәгать контролен кочәйтү, тиешле өлкәдә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

9. Иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) тиешле эшчәнлек өлкәсендәге мәсьәләләргә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына җәмәгать экспертизасы үткәрү, шул исәптән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының муниципаль программалары проектларын карау;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарларын тормышка ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

3) аңа сыйфатны бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советлар функциясе йөкләнгән очракта, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне (алга таба – сыйфатны бәйсез бәяләү) үткәрү Иҗтимагый совет турындагы нигезнамәгә кертелә.

10. Иҗтимагый совет үзенә йөкләнгән бурычлар чикләрендә учреждение эше сыйфатын бәйсез бәяләүне гамәлгә ашыру өчен:

1) бәйсез бәяләү үткәрүгә мөнәсәбәтле оешмалар исемлеген билгели;

2) югарыда күрсәтелгән оешмалар (алга таба – оператор) тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфаты турында мәгълүмат җыю, берләштерү һәм анализлауны гамәлгә ашыра торган оешма өчен техник йөкләмәне эшләү өчен тәкъдимнәр формалаштыра, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында документлар проектларын, шулай ук Башкарма комитет тарафыннан оператор белән төзелә торган муниципаль контрактлар проектларын карап тикшерүдә катнаша;

3) кирәк булганда, оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын билгели (федераль законнар белән билгеләнә торган гомуми критерийларга өстәмә рәвештә);

4) җәмәгать фикерен ачыклау, берләштерү һәм анализлау, социаль хезмәтләр күрсәтүче, шул исәптән, социаль ориентацияле коммерциясез

оешмалар, профессиональ берләшмәләр һәм башка экспертлар тарафыннан формалаштырылган оешмалар рейтингын төзү буенча эш оештыра;

5) Башкарма комитетка түбәндәгеләрне җибәрә:

- сыйфатны бәйсез рәвештә бәяләү нәтиҗәләрен;

- оешманың тиешле эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәрне.

## 3 бүлек. Иҗтимагый совет составы

11. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет, аның рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм Иҗтимагый совет әгъзалары составында, гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмаларның тәкъдимнәре нигезендә формалаштырыла. Иҗтимагый советның персональ составы Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан раслана.

12. Иҗтимагый совет кешесе 5 тән ким һәм 30 дан артык булмаган составта, ирекле катнашу нигезендә формалаштырыла.

13. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән, иҗтимагый һәм башка социаль ориентацияле коммерциясез оешма вәкилләре саналган гражданнар керергә мөмкин. Бу очракта аларның һөнәри сыйфатлары, шул исәптән, Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләрне карап тикшерү өчен кирәкле тиешле белеме, әлеге өлкәдәге эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Әлек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм башка Россия Федерациясе субъектлары вазыйфаларын, Татарстан Республикасы гражданлык хезмәте һәм башка Россия Федерациясе субъектлары вазыйфаларын, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артмаган санда, Иҗтимагый совет әгъзалары булырга мөмкин.

14. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм башка Россия Федерациясе субъектлары вазыйфаларын, Татарстан Республикасы гражданлык хезмәте һәм башка Россия Федерациясе субъектлары вазыйфаларын, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар, суд карары нигезендә юридик сәләтсез дип танылган, хөкем ителгәнлеге бетмәгән һәм алынмаган очракларда, Иҗтимагый совет әгъзалары булырга тиеш түгел.

15. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирү юлы белән сайлана, әгәр алар өчен Иҗтимагый советның барлык әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыграгы тавыш бирсә. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турындагы карар Иҗтимагый совет утырышының беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турындагы мәсьәлә Башкарма комитет Җитәкчесе мөрәҗәгате буенча, шулай ук аларның шәхси гаризасы яки Иҗтимагый советның барлык әгъзаларының гомуми санының биштән беренең тәкъдиме буенча карала.

16. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) аның Иҗтимагый совет составыннан чыгуы турында гариза бирүе;

2) аның сәламәтлек торышы буенча Иҗтимагый совет эшендә катнашуга сәләтсезлеге, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән читләшүе яки башка сәбәпләр булу;

3) судның аңа карата чыгарылган гаепләү карары законлы көченә керү;

4) аны юридик сәләтсез дип тану яки законлы көченә кергән суд карары нигезендә кайдалыгы билгеле булмау;

5) Иҗтимагый совет утырышында катнашучыларның гомуми санының күпчелек тавышы белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча аның тарафыннан этик нормалар тупас бозылу;

6) Россия Федерациясе гражданлыгы булуның туктатылуы;

7) системалы рәвештә (оч тапкырдан артык) нигезле сәбәпсез Иҗтимагый совет утырышлары эшендә катнашмау;

8) системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) нигезле сәбәпсез Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарының йөкләмәләрен үтәмәү;

9) аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына һәм башка Россия Федерациясе субъектлары вазыйфасына, Татарстан Республикасы гражданлык хезмәте һәм башка Россия Федерациясе субъектлары вазыйфасына, муниципаль вазыйфа һәм муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү.

17. Иҗтимагый совет әгъзасы булып торуы Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары күрсәтмәсе нигезендә, шулай ук әлеге нигезләмәнең 16 пунктында каралган хәлләр ачыкланган очракта туктатыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы, үзенең сәламәтлек торышы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген гамәлгә ашыруга сәләтсезлеге, судның аңа карата чыгарылган гаепләү карары законлы көченә керүе, Россия Федерациясе гражданлыгы булып торуы туктатылу очраклары турында мәгълүматларны Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

18. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәләре буенча түбәндәге очракларда туктатып торыла:

1) Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә, аның җинаять эшләгәне өчен гаепләнүен күрсәтү;

2) аңа административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләү;

3) аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат вазыйфасына кандидат, җирле үзидарә органында сайлану вазыйфасына кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яки вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәлүе, шулай ук аның Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кертелүе.

## 4 бүлек. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

19. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Башкарма комитет инициативасы белән үткәрелгән барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, түгәрәк өстәлләрдә) катнашу, федераль законнар нигезендә дәүләт сере, шәхси мәгълүмат турындагы хәбәрләр һәм карау мөмкинлеге чикләнгән мәгълүмат булган хәбәрдән файдалану белән бәйле рәвештә чикләнгән чаралардан кала;

2) инициатив тәртиптә Иҗтимагый советка аналитик язмаларны, докладларны һәм башка мәгълүмати-аналитик материалларны әзерләү һәм җибәрү;

3) Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертү;

4) Иҗтимагый совет утырышларына көн тәртибендәге мәсьәләләрне карау өчен чакырылган затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертү;

5) Иҗтимагый совет составыннан чыгу.

20. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә бурычлы:

1) Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәү;

2) Иҗтимагый совет эшенең тәртибен әлеге нигезнамәдә каралганча белү һәм саклау;

3) Иҗтимагый совет утырышларында шәхси катнашу;

4) Иҗтимагый совет тарафыннан аңа тапшырылган бурычларны хәл итү өчен төзелгән эксперт, эшче төркемнәре, комиссияләре, башка эшче органнар эшендә катнашу.

## 5 бүлек. Иҗтимагый советның эш тәртибе

21. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча Иҗтимагый совет утырышларында расланган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

22. Иҗтимагый советның эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзаларының, Иҗтимагый совет рәисенең һәм Башкарма комитетның тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

23. Иҗтимагый совет утырышлары кименә кварталга бер тапкыр үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Башкарма комитет тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар исемлегендә каралган норматив хокукый актлар проектларына һәм Башкарма комитет карамагындагы Иҗтимагый совет утырышларында алдан каралмыйча кабул ителә алмый торган башка документларга Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатында, Башкарма комитет инициативасы буенча да үткәрелә.

24. Иҗтимагый совет әгъзаларының өчтән ике өлеше катнашкан очракта, Иҗтимагый совет утырышлары тулы хокуклы санала. Иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта үзе катнаша алмаган очракта, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын һәм фикерен язмача, факсимиль яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыру хокукына ия. Ул бу хакта алдан ук Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына, яки Иҗтимагый советның җаваплы секретарена хәбәр итәргә тиеш.

Иҗтимагый совет утырышларында катнашучылар санына үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Иҗтимагый совет тарафыннан норматив-хокукый акт проектларын (норматив-хокукый актлар) карау аларны Башкарма комитет Иҗтимагый советка җибәргән көннән соң ун календарь көн эчендә карала.

Бу очракта тавыш бирүне үткәрү, аның буенча Иҗтимагый советның бәяләмәсен бирү максатында, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру формасында читтән торып тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин. Сораштыру нәтиҗәләре Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертелә, ә ул юкында документны Иҗтимагый совет рәисе урынбасары имзалый.

Мондый тавыш бирү, җибәрелә һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең һәм аларның документальлеген раслауның тәңгәллеген тәэмин итүче почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки башка элемтә аша документлар алмашу юлы белән дә үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү очрагында, Иҗтимагый совет ның барлык әгъзаларына, рәис урынбасарына тәкъдим ителгән көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү каралган норматив-хокукый акт проектлары (норматив-хокукый актлар), аны үткәрү датасына кадәр җиде календарь көн эчендә җибәрелә.

Иҗтимагый совет әгъзалары, кирәк булганда, карала торган норматив-хокукый акт проекты (норматив-хокукый акт) буенча өстәмә материалларны һәм мәгълүматларны Башкарма комитеттан сорап ала алалар.

25. Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

26. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Иҗтимагый совет сайтында яки Башкарма комитет сайтының өстәмә битендә урнаштырыла.

27. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаган очракта, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

28. Иҗтимагый советның аңа йөкләнгән максатлары, бурычлары, вәкаләтләре нигезендә кабул ителгән карарлары рекомендация характерында һәм алар кызыксынган затлар игътибарына Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яисә Иҗтимагый совет карары буенча башка юл белән җиткерелә.

29. Иҗтимагый совет рәисе түбәндәгеләрне башкара:

1) Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

2) Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

3) Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына чыгара;

4) Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

5) Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен раслый;

6) Иҗтимагый совет рекомендацияләрен, беркетмәләрен һәм Иҗтимагый советның башка документларын имзалый;

7) Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

8) Иҗтимагый совет исеменнән запрослар, рекомендацияләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый.

30. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары түбәндәгеләрне башкара:

1) Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмаган вакытта аның функцияләрен үти;

2) Иҗтимагый совет утырышларына әзерлекне оештыра;

3) Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә расларга бирә;

4) Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

31. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре түбәндәгеләрне башкара:

1) утырыш материалларын һәм карар проектларын әзерләүне оештыра;

2) Иҗтимагый совет үткәрүнең урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында Иҗтимагый совет әгъзаларына хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллары белән тәэмин итә;

3) Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота.

32. Иҗтимагый совет утырышларында тыңлау һәм карап тикшерүгә әзерләү өчен, Иҗтимагый совет әгъзалары эшче, эксперт төркемнәргә, башка эшче органнарга берләшә, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килешенү буенча, материаллар әзерләүгә Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне дә җәлеп итә ала.

33. Иҗтимагый совет карары буенча, Иҗтимагый советта карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм бәяләмәләр бирү өчен, Иҗтимагый совет утырышларына Башкарма комитетның тармак органнары, коммерциясез оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет

чакыруы буенча, Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет әгъзасы саналмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга мөмкин.

34. Иҗтимагый совет каравына чыгарыла торган материаллар, Иҗтимагый советның аларны карау планлаштырылган утырышы билгеләнгән датага кадәр 10 календарь көн эчендә Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны тагын да соңрак срокта бирү вакыты Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2016 елның 10 августындагы
4150 нче карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты карамагындагы
Иҗтимагый совет составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Эш урыны, вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Бодрова Ирина Аркадьевна | «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры |
| 2. | Володин Алексей Олегович | «Шәһәр студентлар советы» яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе (килешенү буенча) |
| 3. | Гыйльфанов Рамил Камил улы | Шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары яшьләр советы рәисе (килешенү буенча) |
| 4. | Ипеева Райчка Дмитриевна | Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы (килешенү буенча) |
| 5. | Лундовских Ирина Васильевна | «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| 6. | Минһажева Зөләйха Мөхит кызы | ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, РФ Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы, ТР Язучылар берлеге әгъзасы (килешенү буенча) |
| 7. | Мордовина Инесса Игоревна | «Чаллының күп балалы гаиләләре» региональ иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешенү буенча) |
| 8. | Паймухина Светлана Анатольевна | «Зирәккәй» 96 нчы балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең өлкән тәрбиячесе |
| 9. | Соленов Юрий Владимирович | Татарстан Республикасының «Әтиләр берлеге» региональ иҗтимагый оешмасы рәисе (килешенү буенча) |
| 10. | Фәйзрахманов Рөстәм Тәлгать улы | «Челны» БЯСМ» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф учреждениесе директоры |
| 11. | Фәйрушин Әнәс Батыр улы | ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, «Яран гөл» вокаль ансамбленең сәнгать җитәкчесе, Яр Чаллы татар драма театры хормейстеры (килешенү буенча) |
| 12. | Фәтхуллина Роза | Яр Чаллы инвалидлар иҗтимагый оешмасының |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариф кызы | идарә рәисе (килешенү буенча) |
| 13. | Ханзаров Дамир Шамил улы | «Асылташ» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль ятимнәр йорты» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Г.К. Әхмәтова